**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**ГЛАВА КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**5 декабрь 2023 ел** **№ 10**

**Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы, Березовка поселогы торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены билгеләп кую турында**

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы статьяларына, 2004 нче елның 28 нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясына, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставының 24 нче статьясына таянып, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2023 нче елның 16 нчы декаберендә 9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пунктында, Киндери тимер юл разъезды поселогы, Подстанция Киндери урамы (контора янында) адрес буенча;

1.2. 2023 нче елның 11 нче ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегенең Березовка поселогы торак пунктында, Березовка поселогы, Центральная урамы (8 нче йорт ишегалдында) адрес буенча;

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2.1. Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пунктында: «2024 нче елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Киндери тимер юл разъезды поселогында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм тоту белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.2. Березовка поселогы торак пунктында: «2024 нче елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Березовка поселогы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга:

Березовка поселогын су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү челтәрләрен (су башнялары коймалары) төзү һәм ремонтлау белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станция поселогы, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында, һәм шулай ук Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Биектау муниципаль районы
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф.Хисаметдинов